# ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАР



# ***Җиз бүкән***

***Йөгереклекне, җитезлекне үстерү өчен бу уен күбрәк малайлар арасында җәй көне тышта уйнала.***

***Балалар бер түгәрәк булып, җирдә «җиз бүкән» булып, чүгеп утыралар. Һәрберсенең артында бер малай басып саклап тора. Арада бер малай бүкәнсез калдырылган була. Ул арттан килә дә «сакчы» белән сүз башлый:***

***— Җиз бүкән, җиз бүкән сатлык микән?***

***— Җиз бүкән сатлык икән.***

***— Күпме хак алыр икән?***

***— Хак ярым хак, пот ярым борчак икән.***

***— Әйдә йөгерешеп карыйк, кем килеп алыр икән? — диләр дә түгәрәк тышыннан бер-берсенә каршы йөгереп әйләнәләр. Кем иң элек әйләнеп килеп җитсә, җиз бүкән шуныкы була.***



# *Аю-бүре*

**Балаларның берсе аю яки бүре булып берәр җирдә посып тора. Башкалары урманга «җиләк җыярга» китәләр. Берәү аларга каршы очрап сораша:**

**— Дуслар, кая барасыз?**

**— Кара урманга барабыз.**

**— Кара урманда нишлисез?**

**— Кура җиләк җыябыз.**

**— Җиләк белән нишлисез?**

**— Җиләктән как коябыз.**

**— Бүре килсә нишлисез?**

**— Урман буйлап чабабыз.**

**Аннан соң барысы да күмәкләп җырлыйлар:**

***Җиләк җыям, как коям,***
***Дәү әнигә бүләккә;***
***Монда җиләк күп икән,***
***Аю-бүре юк икән.***

**Бүре яшеренгән җиреннән сикереп чыга да аларны куа башлый. Кемне тотса, шул бүре була.**

**Уен йөгереклек һәм җитезлек сәләтен үстерүгә ярдәм итә.**



# *Алдыр чишмә тамчылый*

***Балалар, икегә бүленеп, бер-берсеннән 20—30 метр ераклыкта тезелеп басалар. Уйнаучылар бер-берсе белән кулга-кул тотынышалар. Беренче яктагылар икенче яктагыларга кычкырып такмаклыйлар:***

***Алдыр чишмә тамчылый,***

***Гөлдер чишмә тамчылый,***

***Ал кирәк, гөл кирәк,***

***Бездән сезгә кем кирәк?***

***Каршы яктагылар җавап бирәләр:***

***Алдыр чишмә тамчылый,***

***Гөлдер чишмә тамчылый,***

***Ал да кирәк, гөл дә кирәк,***

***Роза матур кыз кирәк.***

***Исеме чыккан уенчы каршы якның сафын йөгереп барып өзеп чыгарга тырыша. Өзә алса, бер уенчыны ияртеп, үз ягына алып кайта. Өзә алмаса, шул якта кала. Уен шул тәртиптә бер якта уенчылар беткәнче дәвам итә.***



# *Кошлар һәм читлек*

***Бу уен балаларны тәвәккәл һәм түземле булырга өйрәтә. Ә уенның кагыйдәсе болай.***

***Уенда катнашучыларның яртысы (8—12 кеше), кулга-кул тотынышып, «читлек» хасил итәләр. Калганнары «кошлар» була. Алар төрле якта «очып йөриләр». Уенны алып баручы хәбәр биргәч, «читлек» ачыла — балалар кулларын югары күтәрәләр. «Кошлар» читлеккә кереп-чыгып йөриләр.***

***Алып баручы яңада н хәбәр салгач, «читлек» ябыла — балалар, чүгәли төшеп, кулларын төшерәләр. Түгәрәктән чыга алмый калган «кошлар» тотылган дип исәпләнә. Алар да, кулга-кул тотынышып, «читлек» ясаучылар янына басалар.***

***«Читлек» иркенәя. «Читлек» 3—4 кат ачылып-ябылгач, уенга йомгак ясала. Иң җитезләр билгеләнә. Соңыннан уенчылар урыннарын алмашалар.***

***Искәрмә . Әгәр алып баручы хәбәр салганда «кош»ның башы читлек эчендә кала икән, ул тотылган дип исәпләнә. «Читлек»нең эченә кермичә кырыйда гына «очып йөргән» «кош»лар да тотылганга исәпләнә.***

